Республика Татарстан
Глава Тихоновского сельского поселения
Менделеевского муниципального района

423655, Менделеевский район, с.Тихоново
ул. Шишкина д.3а

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Тихоново авыл җирлеге Башлыгы

423655, Менделеевск районы, Тихоново авылы,
Шишкин урамы, 3а

тел./факс 8/85549/3-43-62, E-mail: Tihon.Men@tatar.ru

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

7 ноябрь, 2023 ел №1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлегендә гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Тихоново авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 17 ноябренә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча Менделеевск муниципаль районының Тихоново авыл җирлеге гражданнарының җыенын этаплап үткәрүне билгеләргә.

1.1. Тихоново авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарыла:

Беренче этап: Коммунистлар урамы 1 нче йорттан 43 нче номерлы йортка кадәр - 15:30 сәг.

Икенче этап: Шишкин урамы 1-56 номерлы йортлар , Яшьләр урамы 3-9нчы йортлар, Үзәк урам 5 й.16:30 сәгать

Өченче этап: Тойма урамы 1 нче йорттан 44 нче йортка кадәр, Урман урамы 1нче йорттан 24 й. кадәр 17:30 сәг.

1.2. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урыны итеп Менделеевск районы, Тихоново авылы, Коммунистлар урамы, 27В йорт адресы буенча урнашкан Тихоново авыл мәдәният йортын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Тихоново авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгән затлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән бер тапкыр бирелә торган түләүне 50%ка киметеп 500 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы:

1. Стенд әзерләү һәм урнаштыру;
2. Зиратка койма кую өчен материаллар алу;
3. ЭЦВ-6 төяү насосын сатып алу - 2 данә.;
4. Һава өрдергеч алу;
5. Кар җыю җайланмасы сатып алу;
6. Кар чистарту;
7. Балалар мәйданчыгы элементларын сатып алу һәм урнаштыру;
8. Тихоново авылында Коммунистлар, Шишкин, Тойма урамнарында асфальт өслекле юлларны һәм чокырларны төзекләндерү
9. Үләннәрне чабу;
10. Чаралар үткәрү өчен проектор сатып алу.

«Риза» "Каршы"

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Тихоново авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Тихоново авыл җирлеге башлыгы А.М. Карманов